КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

« 05 » 12. 2019 г. № 71-п

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында биләгән вакытта дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм счетлары (кертемнәре) булу, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктындагы «и» пунктчасы, «Коррупциягә каршы торуның аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 8 мартындагы 120 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указының 2 пункты, «Биләгән вакытта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм счетлары (кертемнәре) булу, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау» 2015 елның 8 июлендәге УП-542 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында биләгән вакытта дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм счетлары (кертемнәре) булу, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының кушымта итеп бирелә торган исемлеген расларга.

2. Юридик сектор мөдире Ю.С. Климова әлеге боерыкның дәүләт теркәве үтү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше буенча җаваплы зат А.А. Сметанина әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми порталында «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы сайтында «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегенә урнаштырырга тиеш.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен ткишереп торуны «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары И.Ф. Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының
2019 елның 5 декабрендәге
71-п номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында биләгән вакытта дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм счетлары (кертемнәре) булу, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

Вазыйфаларның баш төркеменә карый торган «җитәкчеләр» категориясе кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары;
җитәкченең беренче урынбасары;
җитәкче урынбасары.